ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 579-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.А. Чубаров тарафыннан кертелгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 579-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2024 елның 11 июле
№ 2590-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.А. Чубаров
тарафыннан кертелде

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2 статья. **Урам сәүдәсен һәм халыкның күңел ачуына бәйле булган хезмәтләр күрсәтүне оештыру тәртибен бозу**»;

б) 1 өлешнең беренче абзацында «сәүдә иткән» сүзләреннән соң «йә халыкның күңел ачуына бәйле булган хезмәтләр күрсәткән» сүзләрен өстәргә;

2) түбәндәге эчтәлекле $3.15^1$ статья өстәргә:

«$3.15^1$ статья. **Җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне көчләп тагу**

1. Әйберләр сату-алу, алмашу яисә аларны башка ысул белән алу йә хезмәтләр күрсәтү максатында җәмәгать урыннарында гражданнарга ялыктыргыч бәйләнеп (әлеге Кодексның 3.15 статьясында каралган очраклардан тыш) җәмәгать тәртибен бозган өчен –

кисәтү ясала яисә бер мең биш йөз сум күләмендә административ штраф салына.

2. Ел дәвамында шул ук гамәлләрне кабат кылган өчен –

өч мең сумнан алып биш мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.»;

3) 7.1 статьяда «3.13 – 3.15» саннарын «3.13 – $3.15^{1}$» саннарына алмаштырырга;

4) 8.1 статьяның 14 өлешендә «3.10 (гражданнарга карата),» сүзләреннән соң «$3.15^{1}$» саннарын өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) билгеләнмәгән урыннарда халыкның күңел ачуына бәйле булган хезмәтләр күрсәтүне тикшереп тору механизмын гамәлгә ашыру, шулай ук җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне көчләп тагу максатларында гражданнарга бәйләнүне бетерү максатларында эшләнде.

Бүгенге көндә физик затлар, һөнәри керемгә салым түләүче физик затлар шәһәрнең ачык мәйданчыкларында, үзе теләгән урынны сайлап, курчак костюмындагы затлар белән, хайваннар белән фотога төшү хезмәтләре һәм башка хезмәтләр күрсәтәләр. Еш кына мондый хезмәтләр аларны гражданнарга көчләп тагу, шул исәптән тиешле хезмәт күрсәтүләр бәясен алдап әйтү, юлы белән күрсәтелә. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, мондый хезмәтләрне тарихи урыннарда – Бауман урамында һәм башка әһәмиятле җәмәгать урыннарында күрсәтү Казанның имиджына тискәре йогынты ясый һәм шәһәр халкында, туристларда тискәре хисләр һәм хатирәләр калдыра.

Билгеләнмәгән урыннарда халыкның күңел ачуына бәйле булган хезмәтләр күрсәтүне үтәүгә, шулай ук җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне көчләп тагуга административ контроль чараларын киңәйтү булган проблеманы җайга салу мөмкинлеген бирәчәк.

Закон проекты белән әлеге кимчелекне бетерү максатларында, билгеләнмәгән урыннарда хезмәтләр күрсәткән, шулай ук җәмәгать урыннарында товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне көчләп тагу максатларында гражданнарга бәйләнгән өчен административ җаваплылык билгеләп, тиешле үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә.

Закон проектында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү өлешендә каралган вәкаләтләрне Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының гамәлдәге вазыйфаи затлары билгеләнгән штат саны чикләрендә гамәлгә ашырачак. Тәкъдим ителә торган $3.15^1$ статьяда каралган административ хокук бозулар хакындагы эшләрне карауны җәмәгать судьяларына йөкләргә тәкъдим ителә.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертүне, башка Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итү таләп итми.

**«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнарны таләп итми.